| | |
|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НАДЕЖДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАДЕЖДИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.07.2023 Надеждино ав. №8

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге ягыннан капиталь инвестицияләрне яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында» 2021 елның 16 декабрендәге 12 номерлы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә капиталь кертемнәрне яклау һәм хуплау турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында»28.06.2022 елның 28 июнендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә,Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге ягыннан капиталь инвестицияләрне яклау һәм хуплау турында килешүләр төзү шартлары һәм тәртибе турында» 2021 елның 16 декабрендәге 12 номерлы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты карарына түбәндәнге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктта:

6 нчы пунктчада «транспорт салымы», һәм «,автомобильләргә җиңел һәм мотоциклларга акцизлар» сүзләрен чыгарырга;

түбәндәге эчтәлекле 10 пунктча белән тулыландырырга:

«10) проектны гамәлгә ашыручы оешманың капиталь кертемнәрне яклау һәм хуплау турында килешү төзелгәннән соң өч ел эчендә салым мониторингы формасында салым контроленә күчү бурычы.»;

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең https://nadegd-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча рәсми сайтында бастырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Надеждино авыл җирлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесе Е.В.Савельева